

2026 елнын 1 февралендә Мордовия Главасы Артём Алексеевич Здунов кар десантын житәкләде.
Яшьләр активистлары, Мордовия Республикасы Главасы администрациясе һәм Мордовия Республикасы Хокvмәте, шулай ук шәһәр администрациясе хезмәткәрләре белән бергә республика Главасы Артём Алексеевич Здунов гомуми омәгә чыкты. Россиянен vзәк олешендә һәм бигрәк тә Идел буе федераль округы тобәкләрендә мул явым-тошемнәр аркасында авыллардагы йортлар ишегалларында һәм шәһәр урамнарында кар катламынын биеклеге бик тиз артты. Кар десанты юлындагы объектларнын берсе Володарский урамындагы 1 нче номерлы хатын-кызлар консультациясе булды. Янәшәдәге тротуар, баскыч һәм килvчеләрнен шәхси транспортын кую зонасы чистартылды. Моннан тыш, янәшәдәге торак йортлар территориясендәге vтәли юллар да чистартылды. Шулай ук МГУнын 5 нче корпусы бинасы янында да тәртип урнаштырылды. Боек Ватан сугышы вакытында биредә 326 нчы укчы дивизия штабы урнашкан булган. Ижтимагый акциягә параллель рәвештә муниципаль жирлекләр һәм район vзәкләре, тобәк министрлыклары һәм ведомстволары хезмәткәрләре дә кушылды. Коммуналь хезмәтләр кочәйтелгән режимда эшләде.
Шулай кыш ныклыкка сыный. Мәскәv, Тvбән Новгород, Татарстан, Ульян, Мордовия һәм башка регионнарда башта берничә кон тоташ кар, бозлы янгыр яуды, кочле жил иде, ә атна башы белән кочле суык лар башланды. Регламентланган ос-тенлекләр нигезендә, беренче чиратта магистраль урамнар, vзәк автомобиль юллары, жәмәгать транспорты хәрәкәтенен интенсив маршрутлары, юл чатлары, сәламәтлек саклау һәм мәгариф учреждениеләре механикалаштырылган жыештырылды. Һәр бер авылда да vзәк юлларны даими чистартып тордылар. Мәсәлән, Ләмберә районы авыллары карга каршы корәште, Рузаевканын Татар Пешләсе карны жыештыру буенча кvп коч куйды; Темников районы Митрялы, Тархан, Аксел һәм башка татар авыллары халкы, Торбеевонын Сыркыды, Татар Йонәсе кешеләре карны чистартты; Ромоданово районы Алтар авылы, Кадошкино районы Латышовка, Большие Поляны халкы кvп коч куйдылар. Большие Поляны авыл администрациясе, депутатлары Рашит Рустам улы Капкаев, Руслан Альберт улы Долотказин vз тракторларында авыл картларына, балалары СВОда булганнарнын ишек алларын чистарттылар. Мордовия авыллары активистлары һәйкәлләрдә тәртип урнаштырдылар, яшьләр vз кочләре белән ко не-тоне кар десанты оештырдылар. Ә беренче февральдә халкыбыз, регионыбыз Главасы белән бердәм булып, кар корәv буенча гомуми омәләргә-субботникларга чыктылар.